**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт узучы затларга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү турында

Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы һәм Украина территорияләрендә уздырыла торган махсус хәрби операция вакытында хәрби хезмәт узучы затларга ярдәм күрсәтү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы һәм Украина территорияләрендә уздырыла торган махсус хәрби операция вакытында хәрби хезмәт узучы затларга социаль ярдәм чарасы буларак 260 мең сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне башкару тәртибен расларга;

әлеге Указны үтәү белән бәйле чыгымнарны финанслауны билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә, шулай ук аны гамәлгә ашыру буенча башка карарлар кабул итәргә.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2022 ел, 23 июнь
№ ПУ-438